Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXXVI-5**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 19 ноябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 4 апрелендәге XXVI-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив-хокукый актны гамәлдәге законнарга ярашлы итү максатларында, 2018 елның 3 августындагы "Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 193 маддәсенә үзгәреш кертү турында" 304-ФЗ номерлы, 2018 елның 3 августындагы "Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын үтәү өчен контрольне камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 307-ФЗ номерлы Федераль законнарга, 2018 елның 13 июлендәге "Татарстан Республикасының "Татарстан Республикасының Дәүләт граждан хезмәте турында" гы Законының 10 маддәсенә һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексына үзгәрешләр кертү хакында"гы 50-ЗРТ номерлы, 2018 елның 6 октябрендәге " Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 16 һәм 33 маддәләренә үзгәрешләр кертү турында"гы 64-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законнарына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 4 апрелендәге XXVI-3номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 22 июлендәге № XXVII-6, 2014 елның 14 августындагы №XXXIX-3, 2014 елның 13 декабрендәге №XLII-8, 2015 елның 14 ноябрендәге № V-3, 2016 елның 23 апрелендәге №X-8, 2016 елның 16 ноябрендәге №XIII-9, 2017 елның 29 маендагы №XIX-9, 2017 елның 23 октябрендәге №XXII-6, 2018 елның 24 июлендәге №XXXII-4 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән ) муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.6.3. пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) муниципаль хезмәт стажына яки белгечлек буенча эш стажына, хәзерлек юнәлешенә:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча – муниципаль хезмәт стажы ике елдан ким түгел яисә белгечлек буенча эш стажы, хәзерлек юнәлешенә дүрт елдан ким түгел;

муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары буенча– муниципаль хезмәт стажы бер елдан ким түгел яисә белгечлек буенча эш стажы, хәзерлек юнәлешенә ике елдан ким түгел.”;

2) 2.6.4 пунктындагы “өлкән” сүзен “әйдәүче, өлкән” сүзләренә алыштырырга;

3)түбәндәге эчтәлектәге 2.6.5$^1$ һәм 2.6.5$^2$ пунктлары белән тулыландырырга:

“2.6.5$^1$.Муниципаль хезмәтне алмаштыру өчен белгечлеккә, хәзерлек юнәлешенә зарур булган квалификация таләпләре муниципаль хезмәткәрнең хезмәт урыны инструкциясе белән күздә тотылган очракта белгечлек, хәзерлек юнәлеше буенча хезмәт стажын исәпләгәндә күрсәтелгән стажга әлеге белгечлек, хәзерлекнең әлеге юнәлеше буенча гражданның (муниципаль хезмәткәрнең) белем һәм (яки) күрсәтелгән белгечлек, хәзерлек юнәлеше буенча квалификациясе турында документны алгач эшләгән чорлары кертелә.

2.6.5$^2$. Белгечлеккә, хәзерлек юнәлешенә квалификация таләпләре муниципаль хезмәткәрнең хезмәт урыны инструкциясе белән каралмаган очракта, белгечлек, хәзерлек юнәлеше буенча хезмәт стажын исәпләгәндә күрсәтелгән стажга гражданның (муниципаль хезмәткәрнең) муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча хезмәт урыны бурычларын үтәү өчен зарур булган белемнәрне һәм күнекмәләрне алган эшләү чоры, муниципаль хезмәт вазыйфасын алмаштыру өчен квалификация таләпләренә туры килә торган дәрәҗәдәге һөнәри белем турындагы документ алганнан соң эшләгән чоры кертелә.”;

4) 2.6.9 пунктында “муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфаларын алмаштыру өчен – ярты елдан ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яки бер елдан ким булмаган белгечлек буенча эш стажы” сүзләрен “,муниципаль хезмәтнең баш вазыйфаларын алмаштыру өчен хәзерлек юнәлешенә – ярты елдан ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яки бер елдан ким булмаган белгечлек, хәзерлек юнәлеше буенча эш стажы” сүзләренә алыштырырга;

5) 7.1 маддәсенең 3 пунктында “яллаучы (эш бирүче) вәкиле рөхсәте белән” сүзләреннән соң “, алынган” сүзләре белән тулыландырырга, “федераль законнарда күздә тотылган очракларда, һәм оешма белән идарә итүдә катнашу Россия Федерациясе законнарына ярашлы рәвештә җирле үзидарә органы исеменнән гамәлгә ашырылган очракларда” сүзләрен “гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) булып муниципаль берәмлек торган оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә куючы оешма яки муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы катнашу өлешләре) белән идарә вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актларга туры китереп түләүсез нигездә тәкъдим итү; федераль законнарда каралган бүтән очраклардан” сүзләре белән алыштырырга;

6) 10.2.2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге җөмлә белән тулыландырырга:
“Җирлекләрдә урнашкан авыл торак пунктлары җирле хакимияте вәкаләтләренең бер өлеше йөкләнгән җирле хакимиятнең территориаль органы җитәкчесе

вазыйфасын алмаштыруга конкурс үткәрелгән очракта муниципаль берәмлектә конкурс комиссиясен төзү тәртибе комиссия составына әлеге авыл торак пунктларының һәрберсенең гражданнар җыеннары тарафыннан күрсәтелгән кандидатларны кертүне күз алдында тотарга тиеш.”;

7) 14.4 пунктында “Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән очракларда, күләмнәрдә һәм тәртиптә” сүзләрен “законнарга ярашлы рәвештә” сүзләре белән алыштырырга;

8) 19.1.3 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 2.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

“2.1) тиңдәшле муниципаль органның коррупцион хокук бозуны кылу турында коррупцион һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсенең аны кылуның фактик шартлары бәян ителгән доклады һәм муниципаль хезмәткәрнең фәкать аның ризалыгы белән генә һәм коррупцион хокук бозуны кылу фактын ул таныган шартта язмача аңлатмасы (ышаныч югалту сәбәпле эштән азат итү рәвешендәге җәза кулланудан гайре);”;

9) 19.1.9 пунктының икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Чикләүләр һәм тыюларны үтәмәгән, йөкләмәләрне башкармаган өчен коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән дисциплинар җәза ярамаган эш кылынган көннән өч елдан соң кулланыла алмый.”;

10) 20.6. маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“ 20.6. Шартнамә нигезендә муниципаль хезмәт өчен кадрлар хәзерләү

20.6.1.Муниципаль хезмәтнең югары квалификацияле кадрлар составын булдыру максатларында җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе законнарына ярашлы рәвештә һәм, 2007 елның 2 мартындагы “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, муниципаль хезмәт өчен гражданнарны хәзерләүне шартнамә нигезендә гамәлгә ашырырга мөмкиннәр”.

20.6.2. Аннан соң муниципаль хезмәттә булу йөкләмәсе белән максатчан уку турында шартнамә (алга таба – максатчан уку турында шартнамә) җирле үзидарә органы һәм граждан арасында төзелә һәм укуны тәмамлаганнан соң куелган срок дәвамында гражданның күрсәтелгән җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт узу буенча өстенә алган бурычын күз алдында тота.

20.6.3. Максатчан уку турында шартнамә төзү конкурс нигезендә гамәлгә ашырыла.

20.6.4. Конкурс җирле үзидарә органы тарафыннан игълан ителә һәм җирле үзидарә органында төзелгән конкурс комиссиясе тарафыннан үткәрелә.

20.6.5. Конкурс комиссиясе составына яллаучы (эш бирүче) вәкиле һәм (яки) ул вәкаләт биргән муниципаль хезмәткәрләр (шул исәптән муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча бүлекчәдән һәм юридик (хокук) бүлекчә кадрларыннан, андый бүлекчәләр булмаган очракта – максатчан уку турындагы шартнамә нигезендә граждан муниципаль хезмәт узарга тиеш булган җирле үзидарә органы эшчәнлегендә кадрлар һәм юридик (хокукый) яктан булышлык итүгә җаваплы муниципаль хезмәткәрләр), шулай ук муниципаль хезмәт белән бәйле сораулар буенча бәйсез эксперт-белгеч сыйфатында фәнни, белем бирү һәм (яки) бүтән

оешмаларның персональ мәгълүматларын күрсәтмичә генә чакырылган вәкилләре.Бәйсез экспертлар саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының дүрттән береннән ким булырга тиеш түгел.

20.6.6. Конкурс комиссиясе составы конкурс комиссиясе кабул итә торган карарларга йогынты ясарга ихтималы булган мәнфәгатьләр низагы барлыкка килү мөмкинлеген булдырмаслык итеп формалаштырыла.

20.6.7. Конкурс комиссиясе составы аның рәисеннән, рәис урынбасарыннан, сәркатибеннән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

20.6.8. Максатчан уку турында шартнамә төзүгә конкурс үткәрү хакында мәгълүмат муниципаль хокукый актларны рәсми төстә бастыру гамәлгә ашырыла торган массакүләм басма мәгълүмат чарасында бастырып чыгарылырга һәм күрсәтелгән конкурсны үткәрү датасына кадәр бер айдан да соңга калмыйча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

20.6.9. Конкурс үткәрү турындагы әлеге маддәнең 20.6.8 пунктында күздә тотылган мәгълүматта укып бетергәннән соң гражданнар тарафыннан муниципаль хезмәтнең алмаштырылырга тиешле вазыйфаларының төркемнәре күрсәтелә; бу вазыйфаларга квалификацион таләпләр; әлеге маддәнең 20.6.11 пунктына ярашлы рәвештә конкурска тәкъдим ителә торган документлар исемлеге, аларны кабул итү урыны һәм вакыты; күрсәтелгән документлар кабул ителә торган срок; конкурсны үткәрү датасы, урыны һәм тәртибе; максатчан уку турында шартнамә төзүгә кандидатларны бәяләү һәм сайлап алу өчен файдаланыла торган конкурс процедуралары; язма биремнең темасы (конкурс комиссиясе тарафыннан файдаланыла торган конкурс процедураларының берсе булып язма бирем торган очракта), шулай ук башка мәгълүмати материаллар булырга мөмкин.

20.6.10.Максатчан уку турында шартнамә төзүгә конкурста катнашу хокукына Россия Федерациясе дәүләт телен белүче һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджет средстволары исәбенә уку йортына йөреп укып беренче тапкыр урта һөнәри яисә югары белем алучы гражданнар ия. Күрсәтелгән конкурста катнашучы граждан муниципаль хезмәткә керешү моментына, шулай ук әлеге маддәнең 20.6.34 пунктында каралган барлык срок дәвамында муниципаль хезмәт вазыйфаларын алмаштыру өчен 2007 елның 2 мартындагы “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 25-ФЗ номерлы Федераль закон билгеләгән таләпләргә туры килергә тиеш.

20.6.11. Конкурста катнашырга теләге булган граждан җирле үзидарә органына тапшыра:

1) шәхси гариза;

2) муниципаль хезмәткә керүче граждан тарафыннан җирле үзидарә органына тапшыру өчен федераль законнарга туры китереп расланган форма буенча үз кулы белән тутырылып имзасы салынган һәм фотографиясе теркәлгән анкета;

3) паспорт күчермәсе (паспорт үзе конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә);

4)гражданның хезмәт кенәгәсе яки эшчәнлеген (хезмәтен) раслаучы башка документлары (хезмәт эшчәнлеге элек булмаган очраклардан гайре);

5) 2007 елның 2 мартындагы “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданның муниципаль

хезмәткә керергә һәм анда эшләвенә киртә булырдай авыруының булмавы хакында медицина оешмасы бәяләмәсе;

6) белем бирү оешмасының гражданның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджет средстволары исәбенә уку йортына йөреп укып беренче тапкыр урта һөнәри яисә югары белем алуын раслаучы, шулай ук аның үзләштерә торган белем бирү программасы турында (профессиясенең исемен, белгечлеген яки хәзерлек юнәлешен күрсәтеп), уку планы нигезендә гражданның арадагы аттестацияләрне узу нәтиҗәләре хакында, аның белем бирү оешмасының уставы һәм эчке тәртип кагыйдәләрендә күздә тотылган йөкләмәләрен үтәве турында мәгълүматны үз эченә алган белешмәсе;

7) язма бирем (конкурс комиссиясе тарафыннан файдаланыла торган конкурс процедураларының берсе булып язма бирем торган очракта).

20.6.12. Җирле үзидарә органы җитәкчесе карары буенча әлеге маддәнең 20.6.11 пункты нигезендә граждан тарафыннан тапшырылган персональ һәм башка мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү гамәлгә ашырыла.

20.6.13. Конкурс комиссиясенең дәгъва итүчеләрне бәяләү һәм сайлап алу утырышы әлеге маддәнең 20.6.11 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итү тәгәлләнгән көннән соң 14 календарь көннән дә соңга калмыйча үтә. Конкурс комиссиясе утырышының урыны, датасы һәм вакыты турында конкурс комиссиясе әгъзаларына конкурс комиссиясе сәркатибе тарафыннан мондый утырышны үткәрү көненә кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча белдерү хәбәре җибәрелә. Конкурс комиссиясе утырышын конкурс комиссиясе рәисе үткәрә, ә ул булмаганда – конкурс комиссиясенең рәис урынбасары.

20.6.14. Конкурс комиссиясенең утырышы аның әгъзаларының гомуми санының өчтән икесеннән ким булмаган санда әгъзалар катнашканда вәкаләтле санала.

20.6.15. Конкурс комиссиясе карарлары утырышта катнашучы конкурс комиссиясе әгъзаларының ачык тавыш биреп тавышларның гади күпчелеге белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булган очракта конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүче тавыш биргән карар кабул ителгән булып санала.

20.6.16. Конкурс комиссиясе дәгъва итүчеләрне әлеге маддәнең 20.6.11 пунктының 1-6 пунктчаларында күрсәтелгән тапшырылган документлар нигезендә, шулай ук конкурс процедуралары нәтиҗәләре буенча бәяли. Җирле үзидарә органы карары буенча конкурс процедуралары индивидуаль әңгәмә, тест үткәрү һәм (яки)язма биремне күз алдында тота.

20.6.17. Дәгъва итүче белән индивидуаль әңгәмә ирекле фикерләшү рәвешендә аның алдагы һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсе һәм төренә кагылган тема буенча үткәрелә. Аның барышында дәгъва итүче конкурс комиссиясе әгъзаларының теоретик белемнәрен һәм дәгъва итүченең шәхесен ачыклаучы сыйфатларын бәяләү максатындагы сорауларына җавап бирә.

20.6.18. Дәгъва итүченең теоретик белемнәрен һәм шәхесен ачыклаучы сыйфатларын бәяләү түбәндәге критерийлар буенча гамәлгә ашырыла:

1) теоретик белемнәр дәрәҗәсе;

2) җавапның мантыйкый төзелеше;

3) сөйләмнең грамоталылыгы һәм культурасы;

4) дәгъва итүченең белем бирү оешмасында өлгереш дәрәҗәсе, бастырылган фәнни эшләренең булуы, белем бирү оешмалары үткәрә торган фәнни конференцияләрдә, олимпиада һәм бүтән чараларда катнашуы;

5) һөнәри мотивациянең булуы;

6) җирле үзидарә органнарында практика узуы.

20.6.19. Индивидуаль әңгәмә нәтиҗәләре конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан бәяләнә:

1) өч баллга, әгәр дәгъва итүче тема эчтәлеген эзлекле, тулы күләмдә ачып бирә алса;

2) ике баллга, әгәр дәгъва итүче тема эчтәлеген эзлекле, тулы күләмдә ачып бирсә, әмма төгәлсезлекләр һәм кечкенә ялгышлар җибәрсә;

3) бер баллга, әгәр дәгъва итүче тема эчтәлеген эзлекле, ләкин тулы күләмдә ачып бирмәсә, төгәлсезлекләр һәм кечкенә ялгышлар җибәрсә;

4) ноль баллга, әгәр дәгъва итүче тема эчтәлеген ачып бирә алмаса, төгәлсезлекләр һәм кечкенә ялгышлар җибәрсә.

20.6.20. Утырышта катнашкан барлык конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан индивидуаль әңгәмә нәтиҗәләре буенча дәгъва итүчегә бирелгән баллар кушыла.

20.6.21. Дәгъва итүчеләргә тест үткәрү җирле үзидарә органы тарафыннан төзелгән теория сораулары исемлеге нигезендә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезләмәләрен, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын җирле үзидарә, муниципаль хезмәт, коррупциягә каршы тору өлкәсендә белүне, шулай ук граждан максатчан уку турында шартнамә нигезендә муниципаль хезмәт узарга йөкләмә ала торган җирле үзидарә эшчәнлеге өлкәсенә кагылучы мәсьәләләрне белүен тикшерүгә уздырыла..

20.6.22. Тест үткәрү нәтиҗәләрен бәяләү конкурс комиссиясе тарафыннан тест сорауларына дәгъва итүче биргән дөрес җаваплар саныннан чыгып гамәлгә ашырыла.

20.6.23. Тест нәтиҗәләре буенча дәгъва итүчеләргә конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан куела:

1) биш балл, әгәр тесттагы сорауларның 86-100 процентына дөрес җавап бирелсә;

2) дүрт балл, әгәр тесттагы сорауларның 70-85 процентына дөрес җавап бирелсә;

3) өч балл, әгәр тесттагы сорауларның 51 - 69 процентына дөрес җавап бирелсә;

4) ике балл, әгәр тесттагы сорауларның 35 - 50 процентына дөрес җавап бирелсә;

5) бер балл, әгәр тесттагы сорауларның 20 - 34 процентына дөрес җавап бирелсә;

6) ноль балл, әгәр тесттагы сорауларның 20 проценттан кимрәгенә дөрес җавап бирелсә.

20.6.24. Язма бирем дәгъва итүчеләргә конкурс комиссиясе тәгаенләгән һәм конкурс үткәрү турындагы хәбәрдә күрсәтелгән тема буенча басмача рәвештә хәзерләнә.

20.6.25. Язма биремнең темасы дәгъва итүченең Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезләмәләрен, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын җирле үзидарә, муниципаль хезмәт, коррупциягә каршы тору өлкәсендә белүен, шулай ук граждан максатчан уку турында шартнамә нигезендә муниципаль хезмәт узарга йөкләмә ала торган җирле үзидарә эшчәнлеге өлкәсенә кагылучы мәсьәләләрне белүен ачыкларлык итеп сайлап алына.

20.6.26. Язма биремне бәяләү критерийлары булып бирелгән теманы тулысынча ачу, язып бирүнең грамоталылыгы, язма сөйләмнең культурасы тора.

20.6.27. Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан язма бирем бәяләнә:

1) өч баллга, әгәр дәгъва итүче язма бирем темасы эчтәлеген эзлекле итеп, тулы күләмдә ачып бирсә;

2) ике баллга, әгәр дәгъва итүче язма бирем темасы эчтәлеген эзлекле итеп, тулы күләмдә ачып бирсә, ләкин шуның белән бергә төгәлсезлекләр һәм кечкенә ялгышлар җибәрсә;

3) бер баллга, әгәр дәгъва итүче язма бирем темасы эчтәлеген эзлекле итеп, ләкин тулы күләмдә ачып бирә алмаса, төгәлсезлекләр һәм хаталар җибәрсә;

4) ноль баллга, әгәр дәгъва итүче язма бирем темасы эчтәлеген ачып бирә алмаса.

20.6.28. Утырышта катнашкан барлык конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан язма биремне бәяләү нәтиҗәләре буенча дәгъва итүчегә бирелгән баллар кушыла.

20.6.29. Конкурс кысаларында кулланылган конкурс процедуралары йомгаклары буенча иң күп сандагы гомуми балл җыйган дәгъва итүче конкурста җиңүче булып санала

20.6.30. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүче һәм конкурс комиссиясе сәркатибе кул куйган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

20.6.31. Конкурс комиссиясенең конкурс җиңүчесен билгеләү турындагы карары җирле үзидарә органына конкурста җиңгән дәгъва итүче белән максатчан уку турында шартнамә төзү өчен нигез булып тора.

20.6.32. Конкурста катнашкан гражданнарга аның нәтиҗәләре хакында язмача рәвештә конкурс төгәлләнгән көннән соң бер ай вакыт эчендә хәбәр ителә.

20.6.33. Конкурста катнашу белән бәйле чыгымнар (конкурс үткәрелә торган урынга бару һәм кайту, торак бина яллау, тору, элемтә чаралары хезмәтләреннән файдалану һәм башкалар) гражданнарның үз средстволары хисабына гамәлгә ашырыла.

20.6.34. Максатчан укуны тәмамлаганнан соң муниципаль хезмәтне мәҗбүри узу срогы максатчан уку турындагы шартнамәдә тәгаенләнә. Күрсәтелгән срок җирле үзидарә органы максатчан уку турындагы шартнамә нигезендә гражданга социаль ярдәм чаралары күрсәткән вакыттан ким түгел, әмма биш елдан артык була алмый.

20.6.35. Максатчан уку турындагы шартнамәдәге якларның йөкләмәләре һәм җаваплылыгы Россия Федерациясе законнары нигезендә максатчан уку турындагы шартнамә белән билгеләнә.

20.6.36. Максатчан уку турындагы шартнамә граждан тарафыннан бер тапкыр төзелергә мөмкин.

20.6.37. Максатчан уку турындагы шартнамәдә каралган чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү җирле бюджет средстволары исәбенә гамәлгә ашырыла.";

11) 1 кушымтаның 6 пункты икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Аттестация комиссиясе составына яллаучы (эш бирүче) вәкиле һәм (яки) ул вәкаләт биргән муниципаль хезмәткәрләр (шул исәптән аттестация узарга тиешле муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасын алмаштыра торган бүлекчәдән, муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча бүлекчәдән һәм юридик (хокук) бүлекчә кадрларыннан, андый бүлекчәләр булмаган очракта – аттестация узарга тиешле муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасын алмаштыра торган җирле үзидарә органы эшчәнлегендә кадрлар һәм юридик (хокукый) яктан булышлык итүгә җаваплы муниципаль хезмәткәрләр), шулай ук муниципаль хезмәт белән бәйле сораулар буенча бәйсез эксперт-белгеч сыйфатында фәнни, белем бирү һәм (яки) бүтән оешмаларның персональ мәгълүматларын күрсәтмичә генә чакырылган вәкилләре.Бәйсез экспертлар саны аттестация комиссиясе әгъзаларының гомуми санының дүрттән береннән ким булырга тиеш түгел.".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов